МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

15.08.2024 № 297-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау хакында» 2023 елның 17 маендагы 258-осн номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау хакында» 2023 елның 17 маендагы 258-осн номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнары турында» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибендә:

9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында субсидия күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында закон белән билгеләнә.»;

13 пунктта:

икенче абзацта «чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап» дигән сүзләрне «чыгымнар турында хисап» дигән сүзләр белән алмаштырырга;

өченче абзацта «ирешү турында» сүзләреннән алда «мәгънәләргә» сүзе белән тулыландырырга;

14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирү нәтиҗәләренең һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараның тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларның нәтиҗәләренә ирешү мониторингы Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А.Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 17 маендагы 258-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибенең 14 пунктының икенче абзацы әлеге боерык редакциясендә 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Р.К.Гомәровка йөкләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров